КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 23 март г.Казань № 257

2022 елда Татарстан Республикасында сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән аерым чараларны тормышка ашыру турында» 2022 елның 18 мартындагы 409 номерлы карарын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2022 елда сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча төбәк программаларын тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен;

2022 елда сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча эш бирүчеләрнең чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен эш бирүчеләргә субсидия бирү тәртибен.

2. Бу карарны куллану буенча аңлатмалар бирү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан

гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин